**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2015 Балык Бистәсе штп. № 360пи

2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пунктын, 12 статьясындагы 3 пунктын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 46 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә 2016 елның 1 гыйнварыннан 1,2 номерлы кушымталар нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 5277,28 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хабибуллин

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2015 елның 30 декабрендәге №
360 пи карарына кушымта№1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне тәэмин итү һәм җибәрү | 1480 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) китерү | 800 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм җирләү ) | 2997,28 |
| Барлыгы: | 5277,28 |

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2015 елның 30 декабрендәге №
360 пи карарына кушымта№1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында күмү буенча

хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү | 400 |
| 3. Табут бирү | 1080 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) китерү | 800 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм җирләү  ) | 2997,28 |
| Барлыгы: | 5277,28 |